РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Совет
Шингальчинского сельского поселения
Нижнекамского муниципального района

423554, Нижнекамский район,
с. Шингальчи, ул.Ленина, 64, 1Н

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Түбән Кама муниципаль районының
Шәңгәлче авыл җирлеге
Советы

423554, Түбән Кама районы,
Шәңгәлче авылы, Ленин урамы, 64, 1Н

тел./факс (8555) 43-04-50, электронный адрес: Shingalchinskoe.Sp@tatar.ru,
сайт: www. shingalchinskoe-sp.ru


РЕШЕНИЕ КАРАР

от 14.11.2023 г. № 16

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Шәңгәлче авыл җирлеге Советының «Физик затлар милкәтенә салым турында» 2018 елның 23 июлендәге 13 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлегенә ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «Шәңгәлче авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Шәңгәлче авыл җирлеге Советы карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының Шәңгәлче авыл җирлеге Советының «Физик затлар милкәтенә салым турында» 2018 елның 23 июлендәге 13 номерлы карарына (алга таба - Карар) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

Карарның 2 пунктындагы 1 пунктчасының өченче абзацында «бирелгән» һәм «, дача» сүзләрен төшереп калдырырга;

Карарның 3.1 пунктының алтынчы абзацында «мәйданы 30 квадрат метрдан артмаган» сүзләрен төшереп калдырырга;

Карарның 3.1 пунктындагы җиденче абзацын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны закон нигезендә билгеләнгән тәртиптә игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Р.Х.Сәлимов